Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 55/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чытырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чытырчы торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә:

Чытырчы ав., Зеленая ур., 14 йорт (административ бина);

Чытырчы ав., Зеленая ур., 11б йорт (кибет бинасы).

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Чытырчы авыл җирлеге
башлыгы М.В.Новиков

Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
55/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Лесной | Чытырчы авылы<br>Лесная урамы 1 нче йорттан 19 нчы йортка кадәр | 32 |
| 2 | 2 нче Молодежный | Чытырчы авылы<br>Лесная урамы 19а йортыннан 33 нче йортка кадәр Молодежная урамы 1 нче йорттан 14 нче йортка кадәр | 33 |
| 3 | 3 нче Зеленый | Чытырчы авылы<br>Зелёная урамы 1 нче йорттан 10 нчы йортка кадәр Луговая урамы 1 нче йорттан 17 нче йортка кадәр | 30 |
| 4 | 4 нче Луговой | Чытырчы авылы<br>Центральная урамы 1 нче йорттан 10 нчы йортка кадәр, Центральная урамы, №10а, 11а, № 12, 12а, № 13, № 14 йортлар | 32 |
| 5 | 5 нче Центральный | Чытырчы авылы<br>Центральная урамы 15 нче йорттан 31 нче йортка кадәр | 32 |
| 6 | 6 нчы Полевой | Чытырчы авылы<br>Новосельская урамы 6а йорт<br>Полевая урамы 1 нче йорттан 10а йортка кадәр | 32 |
| 7 | 7 нче Новосельский | Чытырчы авылы, Новосельская урамы 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр<br>Центральная урамы 11 нче йорт,<br>Бурнашево авылы (тулысынча) Кече Полянка авылы (тулысынча) Подколок авылы (тулысынча) | 29 |

# СХЕМА

**одномандатных (или многомандатных) избирательных округов по выборам представительного органа муниципального образования «Четырчинское сельское поселение»**

